РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
422750, село Большая Атня, улица Советская,дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

*«05» июль 2019 ел* № 198

**Опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында**

2008 елның 24 апрелендә чыккан "Опека һәм попечительлек турында"гы 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы "Балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында" гы 423 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 елның 14 сентябрендәге "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 423 номерлы Карарын гамәлгә ашыру турында"гы 334 номерлы боерыгы, 2008 елның 20 мартында чыккан «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында "гы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә районының башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшереп тору тәртибе турындагы Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

2. Опека һәм попечительлек органының балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешманы планлы тикшерү графигын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә районының башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Л. Халиковка йөкләргә.

Әтнә районының
башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Каюмов